КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 6 ноябрь г.Казань № 1053

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү чараларын тормышка ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 3 апрель, 260 нчы карары белән расланган Паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү чараларын тормышка ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү чараларын тормышка ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 3 апрель, 260 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 2 ноябрь, 983 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү чараларын тормышка ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

5 пунктта тиешле килештәге «Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе» сүзләрен тиешле килештәге «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы түбәндәгеләрдә күрсәтелгән чараларны тормышка ашыру максатларында:

бу Тәртипнең 4 пунктындагы «а» һәм «в» пунктчаларында:

дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү чараларын тормышка ашыру максатларында дару препаратлары, медицина әйберләре һәм автомобильләр сатып алу өчен дәүләт контрактларын (шартнамәләр) төзи;

паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү чараларын тормышка ашыру максатларында дару препаратлары, медицина әйберләре һәм автомобильләр сатып алу өчен дәүләт контрактлары (шартнамәләр) төзелгән оешмаларга дәүләт контрактлары (шартнамәләр) шартлары нигезендә акча күчерә;

бу Тәртипнең 4 пунктындагы «б» пунктчасында:

дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү чараларын тормышка ашыру максатларында дару препаратлары, медицина әйберләре һәм автомобильләр сатып алу өчен дәүләт контрактларын (шартнамәләр) төзи;

паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү чараларын тормышка ашыру максатларында дару препаратлары, медицина әйберләре һәм автомобильләр сатып алу өчен дәүләт контрактлары (шартнамәләр) төзелгән оешмаларга дәүләт контрактлары (шартнамәләр) шартлары нигезендә акча күчерә;

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе һәм «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (алга таба – медицина оешмалары) белән, иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең «Электрон бюджет» дәүләт берләштерелгән мәгълүмат системасыннан файдаланып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип формасы буенча Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында килешү төзи;

медицина оешмаларына субсидияләр күчерә.»;

түбәндәге эчтәлекле $7^1$ – $7^3$ пунктлар өстәргә:

«$7^1$. Медицина оешмалары квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның бишенче числосыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча субсидияне тоту турында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына хисаплар кертә.

$7^2$. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы бирелгән акчаны медицина оешмалары тарафыннан түбәндәге очракларда өлешчә яки тулысынча кире кайтаруны тәэмин итә:

әлеге акчага ихтыяҗ булмаганда (кимегәндә);

медицина оешмалары тарафыннан дөрес булмаган хисаплылык бирелгәндә;

медицина оешмалары тарафыннан акча максатчан файдаланылмаганда.

$7^{3}$. Бу Тәртипнең $7^{2}$ пунктында күрсәтелгән очракларда медицина оешмаларына бирелгән акча Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының тиешле таләбен алган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 15 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемөнә кире кайтарылырга тиеш.

Медицина оешмалары тарафыннан акча кире кайтару сроклары бозылганда Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы бу пунктның беренче абзацында билгеләнгән срок тәмамланган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә акчаны Татарстан Республикасы бюджетына законнар белән билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин